**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"13" ноябрь 2023 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Олы Бәрәзә торак пунктында этаплы халык җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылы 2024 елда Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Олы Бәрәзә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү);

2) урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

3) зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

4) урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (вак таш сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү).

5) Олы Бәрәзә авылында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлау (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Олы Бәрәзә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Фатыхова А.В.

Совет Нижнебарасинского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000476